Республика Татарстан
**СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ахмадиева, д.26, п. Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК СОВЕТЫ**

Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы,423368
Телефон: (85559 ) 31-0-97,60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

**РЕШЕНИЕ**
20.05.2022 ел

**КАРАР**
№84

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 27.02.2013 ел, № 82 карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 апрелендәге 123-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы, «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү тәртибе турындагы нигезләмәне гамәлгә кертү тәртибе хакында» Россия Федерациясе Югары Советы карарының һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турындаһәм «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Федераль законның 1 статьясы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Җәлил шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2022 елның 19 маендагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә һәм гавами тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркем тәкъдимнәре нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 27.02.2013 ел, № 82 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре»нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 27 статьяның 5 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6) мондый объектны үзгәртеп корган очракта, капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы, РФ ГК 51 статьясындагы 7 өлешенең 6.2 пунктында күрсәтелгән күпфатирлы йортны үзгәртеп кору очракларыннан тыш, блокланган төзелеш йортларының берсен реконструкцияләгән очракта, барлык йортларның да хокук ияләренең ризалыгы.;

2) 32 статьяның 2 пунктын «зона» сүзләреннән соң «, җир законнары нигезендә чикләре территориаль зоналар чикләрен кисәргә мөмкин булган җир кишәрлегеннән тыш», өченче һәм дүртенче тәкъдимнәрне төшереп калдырырга;

3) 36 статьяның 10 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир асты байлыкларының аерым участокларыннан файдалану илнең оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү, җир асты байлыкларыннан рациональ файдалану һәм саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында чикләнергә яки тыелырга мөмкин. Территорияләрне файдалану өчен махсус шартлары булган торак пунктлар һәм зоналар территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану халыкның тормыш һәм сәламәтлеге, әйләнә-тирә мохитне саклау, биналар һәм корылмаларның сакланышы, шул исәптән тау эшләнмәләренең, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле башка корылмаларның сакланышы куркынычын тудыра алган очракларда чикләнергә яисә тыелырга мөмкин. Аеруча саклана торган табигый территорияләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану аларның территорияләрен махсус саклау режимы нигезендә гамәлгә ашырыла».

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе Р.Ә.Кәримов